ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__1707____ «_27_»____12_______2016 ел

2016-2020 елларга Татарстан
Республикасы Мамадыш муниципаль
районында котыру авыруын профилактикалау
чараларының комплекслы планын раслау турында

«2016-2020 елларга Татарстан Республикасында котыру авыруын профилактикалау чараларының комплекслы планын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 27 гыйнварындагы 78 - р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында терлекләр котыру чире буенча эпизоотик вәзгыятьне яхшырту, әлеге авыруның авыру хайваннардан кешегә күчүенә юл куймау максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2016 - 2020 елларга котыру авыруын профилактикалау чараларының кушымтада бирелә торган комплекслы планын (алга таба - План) расларга (килешү буенча). 2. "Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе" ДБУ, "Мамадыш үзәк район хастаханәсе" ДАССУ, Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнарындагы территориаль бүлегенә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «гражданнарны яклау идарәсе» МКУ идарәсенең районара бүлегенә Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклауга һәм алардан файдалануга, «Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБУЗның Саба районындагы филиалына, Кукмара, Мамадыш районнарында, Мамадыш муниципаль районы җирлекләре башлыкларына, Мамадыш аучылык җәмгыятенә Планның үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән тиешле чаралар күрергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А. П. Смирновага йөкләргә.

Җитәкче И.Э.Фәттахов

Мамадыш
муниципаль районы Башкарма
комитетының
________2016 № ____ карары белән
расланды

**2016-2020 елларга Татарстан
Республикасы Мамадыш муниципаль
районында котыру авыруын профилактикалау
чараларының комплекслы планы**

| № п/п | Чара исеме | Үтәү вакыты | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | 2016-2020 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында котыру авыруын профилактикалау чараларының комплекслы планын эшләү һәм раслау | 2016 ел | Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнарындагы территориаль бүлеге (килешү буенча) |
| 2 | Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2016-2020 елларга котыру авыруын профилактикалау чараларының комплекслы планын үтәү эше турында авыл хуҗалыгы оешмалары һәм формированиеләре җитәкчеләрен тыңлау. | Ел саен | Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнарындагы территориаль бүлеге (килешү буенча) |
| 3 | Дәүләт ветеринария хезмәте, «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССО, кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнарындагы территориаль бүлеге, «Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБУЗның Саба, Кукмара, Мамадыш районнарындагы филиалы арасында авыру очраклары турында мәгълүмат алмашу ашыгыч эпизоотиягә каршы һәм эпидемиягә каршы чаралар күрү өчен кешеләр һәм хайваннар арасында котыру авыруы. | даими | Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнарындагы территориаль бүлеге (килешү буенча), «Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ (килешү буенча), «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (килешү буенча), «Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБУЗның Саба, Кукмара, Мамадыш районнарындагы филиалы (килешү буенча) |
| 4 | Район территориясендә хайваннарны теркәү турында таныклык биреп, хезмәт, | даими | Мамадыш муниципаль районы җирлекләре башлыклары, " Мамадыш районы дәүләт |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сак, ау, йорт этләрен котыру авыруына каршы теркәү һәм вакцинацияләү. | | ветеринария берләшмәсе»ДБУ(килешү буенча), Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсенең районара бүлеге (килешү буенча) |
| 5 | Кыргый ерткыч җәнлекләрне котыру авыруына каршы аларның яшәү урыннарында рабикага каршы вакцина салынган җим салу юлы белән вакцинацияләү. | ел саен яз һәм көз айларында | "Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ (килешү буенча), Мамадыш аучылык җәмгыяте, Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану Идарәсенең районара бүлеге (килешү буенча) |
| 6 | Зоологик фаразны исәпкә алып, эпизоотиягә кадәрге чорда кыргый ерткыч җәнлекләр санын киметү буенча чаралар күрү. | Ел саен | Мамадыш муниципаль районы җирлекләре башлыклары, " Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ (килешү буенча), Мамадыш аучылык җәмгыяте (килешү буенча) |
| 7 | Эпизоотик күрсәткечләр буенча авыл хуҗалыгы хайваннары арасында котыру авыруына каршы прививкалар ясау. | даими | Авыл хуҗалыгы предприятиеләре һәм формированиеләре җитәкчеләре, Мамадыш муниципаль районы җирлекләре башлыклары, " Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ (килешү буенча), Мамадыш аучылык җәмгыяте (килешү буенча),терлек асраучылар(килешү буенча) |
| 8 | Сукбай этләрне һәм мәчеләрне аларның санын җайга салу максатыннан аулау буенча Даими бригадалар төзүне һәм аларның эшләвен тәэмин итү, шулай ук аларны аулау чаралары, махсус кием, махсус аяк киеме, башка индивидуаль саклану чаралары белән тәэмин итү. | даими | Мамадыш муниципаль районы җирлекләре башлыклары, Мамадыш аучылык җәмгыяте (килешү буенча) |
| 9 | Авыл хуҗалыгы җирләрендә тычкансыман кимерүчеләрне юк итү чараларына методик ярдәм күрсәтүне тәэмин итү. | даими | авыл хуҗалыгы предприятиеләре һәм формированиеләре җитәкчеләре |
| 10 | Чистартылган территорияләрдә көз һәм яз айларында тычкансыман кимерүчеләргә каршы профилактик | даими | Мамадыш муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | дератизация чараларын тәэмин итү (торак пунктларны барьерлы дератизацияләү). | | |
| 11 | Торак пунктларны территорияләрне чүп-чардан арындыруга, каты көнкүреш калдыкларын җыю контейнерларын тиешенчә карап тотуга юл куймау өлешендә төзекләндерүне тәэмин итү, каты көнкүреш калдыкларын вакытында чыгару, подвал биналарын карап тоту буенча санитар-эпидемиологик таләпләрне үтәү, аларга терлекләр үтеп керүгә ярдәм итә торган шартларны булдырмау. | Ел саен | Мамадыш муниципаль районы җирлекләре башлыклары, «Мамадыш ТКУ» ҖЧҖ торак фонды хезмәт күрсәтә торган идарәче компанияләр, торак милекчеләре ширкәтләре рәисләре. |
| 12 | Йорт хайваннарының котыру авыруына каршы вакцинация белән тәэмин итү. | даими | "Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе" ДБУ, Мамадыш муниципаль районы җирлекләре башлыклары (килешү буенча), терлекләр тотучылар |
| 13 | Эпизоотик күрсәткечләр буенча авыл хуҗалыгы хайваннары арасында котыру авыруына каршы прививкалар ясау. | даими | "Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе" ДБУ (килешү буенча), авыл хуҗалыгы предприятиеләре һәм формированиеләре җитәкчеләре, Мамадыш муниципаль районы җирлекләре башлыклары, терлекләр тотучылар |
| 14 | «Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ һәм «Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБУЗның Саба, Кукмара, Мамадыш районнарындагы филиалына кешеләрне, авыл хуҗалыгы һәм йорт хайваннарын кыргый ерткыч җәнлекләр, этләр, мәчеләр һәм башка хайваннар тешләгән яки котыру авырулы дип шикләнгән һәр очрак турында хәбәр итү. | по мере выявления | «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ, «Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ, «Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБУЗның Саба, Кукмара, Мамадыш районнарындагы филиалы, Авыл хуҗалыгы предприятиеләре һәм формированиеләре җитәкчеләре (килешү буенча), Мамадыш муниципаль районы җирлекләре башлыклары |
| 15 | Кешеләргә тешләгән һәм башка җәрәхәтләр китергән этләрне, мәчеләрне һәм башка хайваннарны үз вакытында изоляцияләүне һәм 10 көн дәвамында күзәтүне тәэмин итү. | Кирәк булганда | "Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе" ДБУ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | (килешү буенча),терлекләр тотучылар |
| 16 | Котыру авырулы хайваннардан биоматериалны лаборатор тикшерүләр үткәрү. | Беренче тәүлек эчендә | ГБУ "Мамадышское районное государственное ветеринарное объединение» (по согласованию) |
| 17 | «Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ һәм «Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБУЗның Саба, Кукмара, Мамадыш районнарындагы филиалына кыргый хайваннарның үз-үзләрен гадәти булмаган тоту очраклары яки аларның һәлак булуы турында мәгълүмат бирү, кыргый ерткыч җәнлекләр мәетләрен котыру авыруын тикшерү өчен ветеринария лабораториясенә җибәрү. | Кирәк булганда | "Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ (килешү буенча), Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау идарәсенең районара бүлеге (килешү буенча), Мамадыш аучылык җәмгыяте, Мамадыш муниципаль районы җирлекләре башлыклары, хайваннар тотучылар |
| 18 | «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССОның халыкка рабикага каршы ярдәм күрсәтә торган препаратларның (иммуноглобулин вакциналарының) кимеми торган запасын тәэмин итү буенча чаралар күрү. | Ел саен | «Мамадыш үзәк район хастаханәсе " ДАССУ |
| 19 | Хайваннар яки кешеләр арасында котыру авыруының һәр очрагына эпизоотологик-эпидемиологик тикшерү үткәрү, аның учагы чикләрен билгеләү, авыруның сәбәбен ачыклау, инфекция учагын бетерү буенча ашыгыч чаралар күрү. | Ачкланган очракта | «Мамадыш үзәк район хастаханәсе " ДАССУ, «Татарстан Республикасында Гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБУЗның Саба, Кукмара, Мамадыш районнарындагы филиалы ( килешү буенча), " Мамадыш район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ (килешү буенча), Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнарындагы территориаль бүлеге (килешү буенча) |
| 20 | Һөнәри эшчәнлеге котыру вирусы йоктыру куркынычы белән бәйле затларны Татарстан Республикасы бюджетыннан эпидемия күрсәткечләре буенча профилактик прививкалар ясауга бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән профилактик иммунизацияләүне тәэмин итү. | | «Мамадыш үзәк район хастаханәсе " ДАССУ( килешү буенча), Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнарындагы территориаль бүлеге (килешү буенча) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 21 | Котыру вирусы йоктыру куркынычы булган затларга медицина ярдәме күрсәтүне оештыру, гамәлдәге документлар нигезендә дәвалау-профилактик иммунизация курсын уздыру. | даими | «Мамадыш үзәк район хастаханәсе " ДАССУ |
| 22 | Урман хуҗалыгы, торак – коммуналь хезмәтләр хезмәткәрләре, җирлек башлыклары, аучылык белгечләре белән инструктив киңәшмәләр үткәрү. | даими | "Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе" ДБУ (килешү буенча), Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнарындагы территориаль бүлеге (килешү буенча) |
| 23 | Сукбай хайваннарны аулау буенча яңа төзелә торган бригадалар хезмәткәрләре белән инструктив киңәшмәләр үткәрү. | Ел саен | «Мамадыш үзәк район хастаханәсе " ДАССУ "Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе" ДБУ (килешү буенча), Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Саба, Мамадыш, Кукмара районнарындагы территориаль бүлеге (килешү буенча)) |
| 24 | Хайваннардан зыян күргән затларга ярдәм күрсәтү буенча медицина хезмәткәрләре белән семинарлар оештыру һәм уздыру. | Ел саен | «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (килешү буенча), Саба, Кукмара, Мамадыш районнарында «Татарстан Республикасында гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБУЗ филиалы ( килешү буенча) |
| 25 | Халыкны котыру авыруын профилактикалау чаралары һәм этләр һәм мәчеләрне тоту кагыйдәләре турында белешмәлекләр белән тәэмин итү. | Ел саен | «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ (килешү буенча), «Татарстан Республикасында гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБУЗ филиалы Саба, Кукмара, Мамадыш районнарында (килешү буенча) |
| 26 | Массакүләм мәгълүмат чараларыннан котыру авыруын профилактикалау чараларын пропагандалау, халык арасында котыру авыруы һәм аның белән көрәшү чаралары турында аңлату эшләре алып бару. | даими | «Мамадыш үзәк район хастаханәсе» ДАССУ «Мамадыш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ (килешү буенча) һәм «Татарстан Республикасында гигиена һәм |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | эпидемиология үзәге» ФБУЗ филиалы Саба, Кукмара, Мамадыш районнарында (килешү буенча), Саба, Мамадыш, Кукмара муниципаль районнарында Россия кулланучылар күзәтчелеге идарәсенең территориаль бүлеге (килешү буенча) |

Җитәкче урынбасары А.П.Смирнова